**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАРАМАЛЫ ТАУ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2022 елның 23 августы №109

Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советының аерым норматив-хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эш итеп, Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советының Мәгълүмат һәм норматив-хокукый актларын актуальләштерү максатыннан, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы **карар бирде:**

1. Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип танырга:

- «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыелышларын һәм конференцияләрен билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 22 декабрендәге 48 номерлы карары;
- «Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыелышларын һәм конференцияләрен билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 25 ноябрендәге 21 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында: Карамалы Тау ш.т.б., Беренче Май ур., 70 йорт, ҖҮИ административ бинасында мәгълүмат стенды, Беренче Май ур., 70 йорт (ҖҮИНЕҢ административ бинасы).

«Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы А.А. Абдуллин